ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 май 2019ел № 2480

Муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар тарафыннан шәхси ихтыяҗлар өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 маддәсе, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 8 сентябрендәге 5034 нче карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 23 июнендәге 3208 нче, 2018 елның 14 августындагы 4569 нчы, 2018 елның 12 ноябрендәге 6627 нче карарлары редакциясендә) расланган муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.9 пунктта:

- 3 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килү (шундый гариза белән әлеге ширкәт әгъзасы (мондый җир участогы бакчачылык яки яшелчәчелек өчен исәпләнгән очракта) яисә гражданнар тарафыннан шәхси ихтыяҗлар өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан җир участоклары милекчеләре (җир участогы гомуми билгеләнештәге җир участогы булып исәпләнгән очракта) мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);»;

- түбәндәге эчтәлектәге 3.1 пунктча белән тулыландырырга:

«3.1) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы шәхси торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен коммерцияле булмаган оешмага бирелү (әгәр җир участогы әлеге оешманың гомуми файдалануындагы җир участогы булып торса, гариза белән әлеге оешма әгъзасы яисә әлеге оешма мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);»;

- 4, 5 пунктчаларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында гражданнарга яки юридик затларга караган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашу (җир участогында урнаштыру сервитут, җәмәгать сервитуты нигезендә рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки РФ Җир кодексының 39.36 маддәсе нигезендә урнаштырылган объектлар урнаштырылган яисә җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге биналарның, корылмаларның, алар эчендәге бүлмәләрнең, әлеге төзелеше тәмамланмаган объектның милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, шулай ук җир участогы бирү турында гариза бирелгән һәм шул җир участогында урнашкан бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объектына карата рөхсәтсез төзелешне сүтү турында яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул ителгән һәм карарларда күрсәтелгән срокларда Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 маддәсенең 11 бүлегендә каралган йөкләмәләр үтәлмәгән очраклардан тыш);

5) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында дәүләт яки муниципаль милектәге бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашу (җир участогында урнаштыру сервитут, җәмәгать сервитуты нигезендә рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки РФ Җир кодексының 39.36 маддәсе нигезендә урнаштырылган объектлар урнаштырылган яисә җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге биналар, корылмалар, алар эчендәге бүлмәләр, әлеге төзелеше тәмамланмаган объектның милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);»;

- 13 пунктчада «дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 16 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«16) коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы РФ Җир кодексының 39.10 маддәсенең 6 пунктында билгеләнгән чик күләменнән артып китү;»;

2) 1 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карар имзаланган көннән башлап җиде көн срокта аны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 15 маендагы
2480 нче карарына
кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтә

39.5 маддә. Дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын гражданга яки юридик затка милеккә бушлай бирү очраклары

Вәкаләтле орган карары нигезендә дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын гражданга яки юридик затка милеккә бушлай бирү түбәндәгеләр бирелгән очракта гамәлгә ашырыла:

1) анық үсеше турында килешү төзүгә мөнәсәбәтле төзелгән территория чикләрендә барлыкка килгән җир участогын әлеге килешүне төзегән затка;

2) җир участогын милкендә шундый җир участогында урнашкан дини яки хәйрия билгеләнешендәге биналары яки корылмалары булган дини оешмага;

3) территорияне межалау проекты нигезендә барлыкка килгән һәм гражданнар тарафыннан шәхси ихтыяҗлар өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан гомуми билгеләнештәге җир участогы булып исәпләнгән җир участогын, әлеге участокларның мәйданына пропорциональ рәвештә әлеге территория чикләрендә урнашкан җир участоклары милекчеләре булып торган затларга гомуми өлешле милеккә;

4) җир участогын, РФ Җир кодексының 39.10 маддәсе 2 пунктының 6 пунктчасы нигезендә үзенә түләүсез файдалануга җир участогы бирелгән көннән башлап биш ел узгач, граждан әлеге чорда билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә шундый җир участогыннан файдаланган булу шарты белән, шул гражданга;

5) җир участогын, РФ Җир кодексының 39.10 маддәсе 2 пунктының 7 пунктчасы нигезендә үзенә түләүсез файдалануга җир участогы бирелгән көннән башлап биш ел узгач, граждан әлеге чорда билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә шундый җир участогыннан файдаланган һәм муниципаль берәмлектә Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән төп эш урыны һәм белгечлеге буенча эшләгән булу шарты белән, шул гражданга;

6) җир участогын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән очракта һәм тәртиптә өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан мондый гражданнар торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торырга тиеш дигән таләп каралырга мөмкин яки мондый гражданнарның аларны әлеге исәпкә кую өчен нигезләре булу, шулай ук мондый гражданнарга

аларның ризалыгы белән аларга җир участогын милеккә бушлай бирү урынына, торак урыннары белән тәэмин итү буенча социаль ярдәмнең башка чараларын күрсәтү мөмкинлеге билгеләнгән;

7) җир участогын, федераль законнарда каралган очракларда әлеге маддәнең 6 пунктчасында күрсәтелмәгән гражданнарның башка аерым категорияләренә һәм (яки) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмаларга, Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда гражданнарның аерым категорияләренә;

8) даими (сроксыз) файдалану хокукында дини оешмага бирелгән һәм авыл хуҗалыгы производствосы өчен билгеләнгән җир участогын, Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда әлеге оешмага;

9) җир участогын «Дәүләт яисә муниципаль милектәге һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы составына керүче Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир участокларын гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә гражданга;

10) җир участогын «Торак төзелеше үсешенә ярдәм күрсәтү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә;

11) инновацион фәнни-технологик үзәк территориясе чикләренә кертелгән җир участогын «Инновацион фәнни-технологик үзәкләр турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә төзелгән фондка.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Г.К. Әхмәтова